ГОСУДАРСТВЕННЫЙ
КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**БОЕРЫК**

26.11.2018__________ _183-од________

Казан шәһәре

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 2017 елның 24 октябрендәге 134-од номерлы боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенең һәм Татарстан Республикасы муниципаль архивларының комплектлау чыганаклары булган оешмаларының эш башкару буенча инструкциясен, эшләрнең якынча яки индивидуаль номенклатурасын, архив турындагы нигезләмәсен, үзәк эксперт комиссиясе яисә даими эшләүче эксперт комиссиясе турындагы нигезләмәсен килештерү буенча Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында
.

Архив эше өлкәсендә норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенең һәм Татарстан Республикасы муниципаль архивларының комплектлау чыганаклары булган оешмаларының эш башкару буенча инструкциясен, эшләрнең якынча яки индивидуаль номенклатурасын, архив турындагы нигезләмәсен, үзәк эксперт комиссиясе яисә даими эшләүче эксперт комиссиясе турындагы нигезләмәсен килештерү буенча Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 24 октябрендәге 134-од номерлы боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенең һәм Татарстан Республикасы муниципаль архивларының комплектлау чыганаклары булган оешмаларының эш башкару буенча инструкциясен, эшләрнең якынча яки индивидуаль номенклатурасын, архив турындагы нигезләмәсен, үзәк эксперт комиссиясе яисә даими эшләүче эксперт комиссиясе турындагы нигезләмәсен

килештерү буенча Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Дәүләт комитетының урнашу урыны һәм аның почта адресы: 420107, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Ново-Песочная урамы, 44 нче йорт.

Дәүләт комитетының электрон адресы: prm.arhive@tatar.ru.

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-95-62, 222-95-68.

Дәүләт комитетының эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе 9.00 алып 18.00 кадәр, җомга 9.00 алып 16.45 кадәр, төшке аш 12.00 алып 12.45 кадәр.

Гаризаларны кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен Дәүләт комитетының эш сәгатьләрендә.

Җәмәгать транспортында килү:

«Сукно бистәсе метросы» тукталышына кадәр:

- автобуслар № 1, 4, 25, 43, 102;
- метро «Сукно бистәсе» станциясе;

Павлюхин тукталышына кадәр:

- автобуслар № 4, 25, 31, 37, 43, 71, 102;
- троллейбуслар № 6, 8, 12.

Керү үткәргеч карта һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ буенча.»;

1.4.3 пунктта:

2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) мәгълүмат стендларына урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 1.4.1, 1.6, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы белешмәләрне үз эченә ала.»;

3 пунктчаның өченче абзацында «(https://uslugi.tatar.ru/)» сүзләрен «(https://uslugi.tatarstan.ru/)» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

«Россия Федерациясендә архив эше турында» 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 125-ФЗ номерлы Федераль закон) (Собрание законодательства Российской Федерации, 2004, № 43, ст. 4169, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Собрание законодательства Российской Федерации, 2010, № 31, ст. 4179, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (Собрание законодательства Российской Федерации, 2011, № 15, ст. 2036, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы

Указы (алга таба - 601 номерлы Указ) (Собрание законодательства Российской Федерации, 2012, № 19, ст. 2338);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль башкарма хакимият органнарында эш башкару кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 15 июнендәге 477 номерлы карары (алга таба – 2009 Кагыйдәләре) (Собрание законодательства Российской Федерации, 2009, № 25, ст. 3060, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Мәдәният һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм дәүләт һәм муниципаль архивларда, музейларда һәм китапханәләрдә, фәнни оешмаларда башка архив документларын саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм адардан файдалануны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2007 елның 18 гыйнварындагы 19 номерлы боерыгы (алга таба – 2007 Кагыйдәләре) (Бюллетень нормативных актов федеральных органов исполнительной власти, 2007, № 20, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Мәдәният һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының «Оешмаларның фәнни-техник һәм җитештерү эшчәнлегендә барлыкка килә торган типлаштырылган архив документларының саклау сроклары күрсәтелгән исемлеген раслау турында» 2007 елның 31 июлендәге 1182 номерлы боерыгы (алга таба – 2007 Исемлеге) (Бюллетень нормативных актов федеральных органов исполнительной власти, 2007, № 46, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының «Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар эшчәнлеге процессында барлыкка килә торган типлаштырылган идарә архив документларының саклау сроклары күрсәтелгән исемлеге»н раслау турында» 2010 елның 25 августындагы 558 номерлы боерыгы (алга таба – 2010 Исемлеге) (Бюллетень нормативных актов федеральных органов исполнительной власти, 2011, № 38, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм оешмаларда башка архив документларын саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм адардан файдалануны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 31 мартындагы 526 номерлы боерыгы (алга таба – 2015 Кагыйдәләре) (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 10 сентябрь, басылып чыгу номеры: 0001201509100001);

Федераль техник җайга салу һәм метрология агентлыгының «Мәгълүмат, китапханә һәм нәшрият эше буенча стандартлар системасы. Оештыру-йөкләү документациясе. Документларны рәсмиләштерүгә карата таләпләр» ГОСТ Р 7.0.97-2016 Россия Федерациясе Милли стандартын раслау турында» (алга таба – ГОСТ Р 7.0.97-2016) 2016 елның 8 декабрендәге 2004-ст номерлы боерыгы («Официальные документы в образовании» нәширлеге, № 18, июнь, 2017, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Федераль архив агентлыгының «Оешма архивы турында үрнәк нигезләмәне раслау турында» 2018 елның 11 апрелендәге 42 номерлы боерыгы (алга таба – Архив турында үрнәк нигезләмә) (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2018, 15 август, басылып чыгу номеры: 0001201808150016);

Федераль архив агентлыгының «Оешманың эксперт комиссиясе турында үрнәк нигезләмәне раслау турында» 2018 елның 11 апрелендәге 43 номерлы боерыгы (алга таба – ЭК турында үрнәк нигезләмә) (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2018, 18 июнь, басылып чыгу номеры: 0001201806180025);

«Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 63-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы (pravo.tatarstan.ru), 2017, 21 июль, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары) («Сборник постановлений и распоряжений Кабинета Министров Республики Татарстан и нормативных актов республиканских органов исполнительной власти» журналы, 2010, № 46, ст. 2144, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2016 елның 9 августындагы 541 номерлы карары (алга таба – Нигезләмә) («Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы, 2016, № 13, ст. 0384, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының экспертиза-тикшерү һәм методика комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 14 декабрендәге 117-од номерлы боерыгы (алга таба – ЭТМК турында Нигезләмә) (Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы (pravo.tatarstan.ru), 2016, 27 декабрь);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының экспертиза-тикшерү һәм методика комиссиясе эшләү регламентын раслау турында» 2017 елның 15 февралендәге 015-од номерлы боерыгы (алга таба – ЭТМК эшләү регламенты) (Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайты (www.arhiv.tatarstan.ru).»;

1.6 пунктта:

7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтәге эш урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яки авыл җирлегендә төзелгән территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).»;

түбәндәге эчтәлекле тугызынчы абзац өстәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә дәүләт хезмәте күрсәтү турында сорату (алга таба – сорату) күз алдында тотыла (210-ФЗ номерлы Федераль закон). Сорату оешма бланкында ирекле рәвештә рәсмиләштерелә.»;

1.14 һәм 1.15 пунктларны үз көчләрен югалткан дип таныргa;

2 бүлектә:

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Эш башкару буенча аңлатманың, архив турында нигезләмәнең, ГОСТ Р 7.0.97-2016 нигезендә үзәк эксперт комиссиясе яки даими эшләүче эксперт комиссиясе турында нигезләмәнең, 2015 Кагыйдәләренә 25 нче кушымта нигезендә үрнәк яки индивидуаль делолар номенклатурасының соңгы битенең сулъяк аскы өлешендә “Имза” реквизитыннан аста урнашкан документны килештерү грифы рәвешендә рәсмиләштерелгән Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетның экспертиза-тикшерү һәм методика комиссиясе (алга таба – ЭТПК) карары.<br>Документларны килештерү йә, законнарга сылтама белән хокук бозылуга күрсәтеп, документларны килештерүдән баш тарту турында ЭТПК әгъзасы бәяләмәсе. | 2007 Кагыйдәләре<br>2009 Кагыйдәләре<br>2015 Кагыйдәләре<br>2007 Исемлеге<br>2010 Исемлеге<br>Архив турында үрнәк нигезләмә<br>ЭК турында үрнәк нигезләмә |

2.4 пунктның «Стандартка карата куелган таләпләрнең эчтәлеге» графасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору Россия Федерациясе законнарында каралмаган.»;

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Законнар яки башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри | Дәүләт архивын, муниципаль архивны туплау чыганагы булган оешма җитәкчесе яки аның урынбасары тарафыннан имзаланган документларны килештерү турында сорату (оешма бланкындагы хат);<br>ЭТМК эшләү регламенты белән билгеләнгән форма буенча дәүләт | ЭТМК эшләү регламенты |

| | | |
|---|---|---|
| булган хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле булып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның, шул исәптән электрон рәвештәге, тулы исемлеге, аларны тапшыру тәртибе | архивы һәм муниципаль архив тәкъдимнәре;<br>2 нөсхәдә делоларның үрнәк номенклатурасы проекты яки 4 нөсхәдә делоларның индивидуаль номенклатурасы;<br>2 нөсхәдә эш башкару буенча аңлатма;<br>2 нөсхәдә архив турында нигезләмә;<br>2 нөсхәдә үзәк эксперт комиссиясе (алга таба – ҮЭК) яки эксперт комиссиясе (алга таба – ЭК) турында нигезләмә;<br>делоларның үрнәк яки индивидуаль номенклатурасын, эш башкару буенча аңлатманы, архив турында нигезләмәне, ГОСТ Р 7.0.97-2016 нигезендә рәсмиләштерелгән ҮЭК яки ЭК турында нигезләмәне килештерү хакында дәүләт архивын, муниципаль архивны туплау чыганагы булган оешманың ҮЭК яки ЭК беркетмәсе (беркетмәсеннән өземтә);<br>дәүләт архивының яки муниципаль архивның югарыда күрсәтелгән документларга кагылышлы бәяләмәсе.<br>Электрон рәвештә тапшырылган документлар 210-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә туплау чыганагы булган оешма җитәкчесенең яки аның урынбасарының электрон имзасы белән таныкланган булырга тиеш. | |

5 бүлектә:

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар Дәүләт комитетының, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Дәүләт комитеты вазыйфаи затының йә дәүләт хезмәткәренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

Дәүләт комитеты белгечләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына), карарларына шикаять Дәүләт комитеты рәисе исеменә бирелә.

Дәүләт комитеты башлыгы кабул иткән карарларга, аның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы соратуны теркәү вакыты бозылу;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы бозылу;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документлар яки мәгълүмат тапшыруны йә гамәлләр башкарруны мөрәҗәгать итүчедән таләп итү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында тапшыру каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләүне мөрәҗәгать итүчедән таләп итү;

7) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты тарафыннан җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән аларның баш тартуы йә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогы яки тәртибе бозылу;

9) әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында туктатып тору нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул иткәндә йә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны мөрәҗәгать итүчедән таләп итү.»;

5.2 пунктның икеенче абзацында «(https://uslugi.tatar.ru/)» сүзләрен «(https://uslugi.tatarstan.ru/)» сүзләренә алмаштырырга;

5.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5. Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документларны (булган очракта) йә аларның күчермәләрен тапшыра ала.»;

5.6 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында түләү алу каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.»;

түбәндәге эчтәлекле $5.7^1$, $5.7^2$ пунктлар өстәргә:

«5.7[1]. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылса, мөрәҗәгать итүчегә җавапта дәүләт хезмәте күрсәткәндәге ачыкланган хокук бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында Дәүләт комитеты тарафыннан башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук уңайсызлыклар китергән өчен гафу сорала һәм дәүләт хезмәте күрсәтелүдән файдалану өчен мөрәҗәгать итүче алга таба башкарырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.7[2]. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип табылса, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.».